ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

29.01.2021 ел.

с. Майдан

№3

2021нче елга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Мәет җирләү һәм күмү эше турында» 1996нчы елның 12нче гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 нчы статьясындагы 3нче пункты һәм 12нче статьясындагы 3нче пункты, «2021нче елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021нче елның 28нче гыйнварындагы 73нче номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны һәм «Тарифлар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010нчы елның 15нче июнендәге 468нче номерлы Федераль законы, Мәйдан авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2021нче елның 1нче февраленнән башлап, 1нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә, Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 6424,98 сум күләмендә хезмәт күрсәтү бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Мәйдан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В. В. Михеев

Мәйдан  авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2021нче елның  29нчы
гыйнварыннан 3нче номерлы
карарына
1нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан  авыл җирлегендә 2021нче елның 1нче февраленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2.  Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3322,18 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка озату | 1030,12 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2072,68 |
| Барлыгы | 6424,98 |

Мәйдан  авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2021нче елның  29нчы
гыйнварыннан 3нче номерлы
карарына

2нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан  авыл җирлегендә 2021нче елның 1нче феврaленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | —- |
| 2. Мәетне кәфенләү | 614,71 |
| 3. Җирләү өчен  табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 2707,47 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү | 1030,12 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2072,68 |
| Барлыгы | 6424,98 |